**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге составына керүче Шумково торак пунктында узган гражданнар җыены**

**КАРАРЫ**

1 апрель, 2024 ел № 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Шумково авыл җирлегеУставына,Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 октябрендәге 14 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлегенең Шумково торак пунктында гражданнарның үз ара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында» 2024 елның 21 мартындагы 3номерлы карары нигезендә, гражданнар җыенының 2024 елның 1 апрелендәге 3 номерлы йомгаклау беркетмәсен игътибарга алып,Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлегенең Шумково торак пунктында узган гражданнар җыены КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге составына керүче Шумково торак пунктында узган гражданнар җыенының 2023 елның 22 ноябрендәге 1 номерлы карарына, 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләрк ертергә:

«1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авылы җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән,көндез укып белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан гайре, һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 500 (бишйөз) сум күләмендә үз ара салым кертергә, тупланган акчаларны, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәлитүгә юнәлтеп, түбәндәге эшләрне башкару өчен файдаланырга:

– торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагыжирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тотуга;

- су белән тәэмин итү һәм субүлү системаларын, суэтем башняларын, скважиналарны һәм башка су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны тәэмин итүче инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлауга, аны чистартуга, транспортлауга һәм халыкка су бирүгә (җибәрүгә);

– урам утларын карап тоту (урнаштыруга);

– торак пункт территориясен төзекләндерүгә;

– каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларыт өзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерүгә;

- традицион җирләү (мәет кую) урыннарын ремонтлауга, киртәләүгә, төзекләндерүгә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсемуниципаль районы Шумково авыл җирлегенең Шумково торак пунктының түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында:Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Шумково авылы, Үзәк урам, 4 нче йорт, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шумково авыл җирлеге башлыгы урынбасары Моталлапов Н.Н.